МЭР
ГОРОДА БАВЛЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.09.2019 Баулы шәһәре № 33

Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы шәһәренең Островский тыкрыгы буенча Беренче Май урамына кадәр автомобильләр хәрәкәте маршрутын үзгәртү турында»гы карары проекты буенча Баулы шәһәрендә ачык тыңлаулар билгеләү турында

Баулы шәһәренең Островский тыкрыгы буенча Беренче Май урамына кадәр автомобильләр хәрәкәте маршрутын үзгәртү һәм автомобильләр хәрәкәте карта-схемасына үзгәрешләр кертү турында фикер алышуда катнашуга Баулы шәһәрендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә

К А Р А Р И Т Ә М:

1. Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы шәһәренең Островский тыкрыгы буенча Беренче Май урамына кадәр автомобильләр хәрәкәте маршрутын үзгәртү турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2019 елның 4 октябрендә 9:00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында үткәрергә: Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4нче йорт, 20нче кабинет.

2. Ачык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы итеп Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакировны (алга таба – «Баулы шәһәре» Башкарма комитеты җитәкчесе) билгеләргә.

3. «Баулы шәһәре» Башкарма комитеты җитәкчесе тәэмин итәргә тиеш:

- ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү буенча законнар, муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәүне;

- кызыксынган затларга ачык тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат бирүне.

4. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларда чыгыш хокукы белән катнашуга гаризалар Баулы шәһәре, Җиңү мәйданы, 4нче йорт, 23нче кабинет адресы буенча кабул ителә (эш көннәрендә 9:00 сәгатьтән 15:00 сәгатькә кадәр).

5. Кушымта нигезендә, керә торган тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә.

6. Әлеге карарны, Баулы шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Баулы шәһәренең Островский тыкрыгы буенча Беренче Май урамына кадәр автомобильләр хәрәкәте маршрутын үзгәртү турында»гы карары проектын Баулы муниципаль районының интернет челтәрендәге httpp//bavly.tatar.ru адресы буенча урнашкан сайтында һәм htpp//pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы шәһәре Мэры Р.Х. Гатиятуллин

БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ БАУЛЫ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Баулы муниципаль районы
Башлыгының 2019 елның
«13» 09
кабул ителгән 33
карарына кушымта

# Керә торган тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Бакиров Данияр Ленар улы | - | «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем җитәкчесе; |
| Чахеева Светлана Юрьевна | - | «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты баш белгече; |
| Корбанов Карим Фатхетдин улы | - | Баулы шәһәр Советы депутаты, «Актүбә СМУ» ҖЧҖнең Баулы участогы башлыгы (килешү буенча); |
| Михайлова Алина Анатольевна | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хасиятуллина Роза Ильяс кызы | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Каһиров Радик Әхмәтсафа улы | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Галиев Рәмис Фоат улы | - | Россия Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ бүлегенең Баулы районы буенча юл хәрәкәте куркынычсызлыгы баш дәүләт инспекторы, полиция майоры (килешү буенча). |